КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1300

Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан сәләтлеләр ачык университеты 2.0» автоном коммерциячел булмаган оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2015 ел, 09 июль, 501 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 29 декабрь, 1300 нче
карары белән расланды

Коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм коммерциячел булмаган оешмаларга сәләтле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны озатып бару чараларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия Татарстан Республикасы Министлар Кабинетының «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 3 декабрь, 943 нче карары белән расланган «2015 – 2020 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү» дәүләт программасы (алга таба – дәүләт программасы) чараларын гамәлгә ашыру белән бәйле, Татарстан Республикасында балалар һәм яшьләрнең интеллектуаль-иҗади потенциалы мөмкинлекләрен популярлаштыруга, талантлар белән идарә итүдә ведомствоара хезмәттәшлекне үстерүгә, проект-тикшеренү мәйданчыклары челтәрен үстерүгә, балалар һәм яшьләрнең кыйммәтле ориентациясен булдыруга, шул исәптән талантка идарә итү һәм үстерү өлкәсендә укыту-методик һәм публицистик материалларны эшләү, бастыру һәм таратуны кертеп, курслар, семинарлар, тренинглар рәвешендә балаларга һәм яшьләргә өстәмә белем бирүгә, мәгариф, сәләтле яшьләрне эш белән тәэмин итү һәм эшкә урнаштыру өлкәсендә күргәзмә эшчәнлеген оештыруга юнәлдерелгән чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында дәүләт (муниципаль) учреждениеләр булмаган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә.

3. Субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш идарә итүче булып Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга гамәлгә ашырыла.

5. Субсидияләр максатчан характерда һәм башка максатларга җибәрелә алмый.

6. Субсидияләр бирү өчен коммерцияле булмаган оешмаларны сайлап алу критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

яшьләр сәясәте өлкәсендәге эшчәнлек;

субсидияләр бирү турында гариза бирү көненә кадәр кимендә ике ел дәүләт программасы чараларын гамәлгә ашыру тәҗрибәсе булу.

7. Субсидияләр түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциячел булмаган оешмаларга бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәрге айның беренче көненә (алга таба – килешү):

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча үтәлмәгән бурычлары юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, кире кайтару буенча һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында башка вакыты чыккан бурычлары юк;

үзгәртеп кору, бетерү, банкротлык процессында түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган Россия юридик заты булып тормаган;

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучылар булып тормый.

8. Субсидия алу өчен коммерциячел булмаган оешмалар Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык билгеләгән формада субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза);

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча, финанс-икътисадый нигезләү кушымтасы белән чыгымнар сметасы;

коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе яки аның вәкаләтле заты вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре;

гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга барлык үзгәрешләр турында документлар күчермәләре;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктларында билгеләнгән критерийлар һәм таләпләргә туры килүне раслый торган, җитәкче (башка вәкаләтле зат) тарафыннан имзаланган документлар.

9. Документларның күчермәләре коммерциячел булмаган оешма җитәкчесе имзасы белән таныкланырга, шулай ук коммерциячел булмаган оешма мөһере белән (булган очракта) беркетелергә тиеш.

10. Министрлык Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар белән гаризаны алар кергән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә теркәүне гамәлгә ашыра.

11. Министрлык теркәлгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

12. Кабул ителгән карар нәтиҗәләре турында хәбәрнамә тиешле карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә коммерциячел булмаган оешма тарафыннан Министрлыкка җибәрелә.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, гаризада баш тарту өчен нигез күрсәтелә.

13. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

коммерциячел булмаган оешманың әлеге Тәртипнең 6, 7 пунктларында каралган таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 8 пунктында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау);

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 9 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциячел булмаган оешма тарафыннан тәкъдим ителгән мәгълүматның дөрес булмавы.

14. Субсидия бирү Министрлык һәм коммерциячеле булмаган оешма арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган үрнәк форма буенча субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия бирү нәтиҗәлелегенең күрсәткечләре әһәмияте, субсидия күчерү тәртибе, субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү вакыты, формасы, шул исәптән субсидия куллануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында, аны биргәндә билгеләнгән шартларны бозган очракта субсидия кире кайтару очраклары, финанс елында кулланылмый калган субсидияләрне агымдагы финанс елында кире кайтару тәртибе һәм очраклары, финанс белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия калдыклары, Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә югары технологияле чит ил җиһазларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (җибәргәндә) гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш, чит ил валютасы акчалары исәбеннән субсидияләр алуны тыю, килешүләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торучы коммерциячел булмаган оешманың һәм коммерциячел булмаган оешмаларның ризалыгы тора, субсидия бирү турында килешүләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан коммерциячел булмаган оешма тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыру өчен төзелгән.

15. Субсидияләр бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре дәүләт программасының тиешле чараларының ахыргы нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары нигезендә билгеләнә (план күрсәткеченең 95 проценттан да ким түгел).

16. Субсидия зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләнә:

С = Зт. + Зтэ. + Зт.р.у. + Зк. + Зос. + Зпр.,

монда:

С – бирелә торган субсидия күләме, сум;

Зт. – эш хакына исәпләнгән иминият кертемнәрен исәпкә алып, хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;

Зтэ. – бәйсез экспертлар, штаттан тыш хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү;

Зт.р.у. – товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, аренда түләве;

Зк. – командировка чыгымнары;

Зос. – төп чаралар һәм матди булмаган активларны сатып алу;

Зпр. – субсидия бирү максатларына турыдан-туры бәйле бүтән нигезле чыгымнар.

17. Министрлык килешү төзелгәннән соң 10 көн эчендә коммерциячел булмаган оешманың Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына субсидия күчерә.

18. Коммерциячел булмаган оешма килешүдә билгеләнә торган вакытлар һәм форма нигезендә Министрлыкка субсидия куллану һәм килешү нигезендә субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисап тапшыра.

19. Субсидия бирү турында килешүдә каралган очракларда субсидиянең хисап финанс елында файдаланылмаган калдыклары коммерциячел булмаган оешма тарафыннан хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

20. Министрлык коммерциячел булмаган оешманың агымдагы финанс елында файдаланылмый калган субсидияләргә ихтыяҗы булганда, күрсәтелгән калдыкны чираттагы финанс елында шул ук максатларга һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә файдалану турында карар кабул итәргә хокуклы.

21. Законнар нигезендә Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәлүне тикшерүне гамәлгә ашыралар.

22. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча субсидияләр бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен бозу фактлары ачыкланса, коммерциячел булмаган оешма Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 30 көн эчендә акчаларны Татарстан Республикасы бюджеты керемено кире кайтарырга тиеш:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган очракта тулы күләмдә;

субсидияләрдән файдалану турында хисап тапшырылмаган очракта тулы күләмдә;

нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешмәгән очракта, субсидия бирүнең ирешелмәгән һәр нәтиҗәлелек күрсәткече өчен 5 процент күләмендә;

субсидия акчаларын максатсыз файдалану ачыкланган очракта, максатчан билгеләнеше буенча файдаланылмаган субсидия күләмендә.

23. Субсидия алучы әлеге Тәртипнең 19 һәм 22 пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срокларын бозган очракта, Министрлык, субсидия кире кайтару срогы чыккан көннән соң, эш көннәрендә исәпләнгән 7 көн эчендә, законнарда билгеләнгән тәртиптә күрсәтелгән акчаларны Татарстан Республикасы бюджетына кайтару буенча чаралар күрә.

24. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын контрольдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.